СОВЕТ ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Ш.Маннура, д.72а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

Ш.Маннур ур., 72а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-82; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение                                                                 Карар

«11» апрель 2018 ел                                                  № 1-31

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2017 елның 13 апрелендәге 711/пр номерлы «Җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик рекомендацияләрне раслау турында» боерыгы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Олыяз авыл җирлеге территориясендә объектларны төзекләндерүнең бердәм таләпләрен билгеләү максатларында, Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен икенче укылышта 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга(халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә (pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге башлыгы И.Я.Хаевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе                                        /И.Я.Хаев/